РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» февраля 2026 ел г. Альметьевск № 277

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районына тапшыру турында Әлмәт шәһәр Советы тәкъдимнәрен кабул итү хакында» 2023 елның 29 мартындагы 208 номерлы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы вәкаләтләрен тапшыру турында» 2023 елның 29 мартындагы 100 номерлы Татарстан Республикасы шәһәр Советы карары, Татарстан Республикасы Социаль фонды бүлегенең Әлмәт районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) 20265 елның 26 гыйнварындагы 51-34-09/131мөрәҗәгате нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталарга ярашлы рәвештә 9 678,63 сум күләмендә дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында»2025 елның 05 февралендәге 258 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

заказ № 4553-940

Әлмәт муниципаль районы
Башкарама комитеты
“ 19 ” февраль 2026 ел № 277
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
БӘЯСЕ

| №№ п/п | Хезмәтләр исеме | Хезмәтләр бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 635,82 |
| 3 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,43 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдинов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарама комитеты
“19” февраля 2016 ел № 277
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
БӘЯСЕ

| №№ п/п | Хезмәтләр исеме | Хезмәтләр бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү | 3 304,27 |
| 3 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 331,54 |
| 4 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,44 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.А. Ямалетдинов